КАРАР

№ 1

05 декабрь 2019 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы җирлегендә Байлангар авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 02.12.2019, 03.12.2019 елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы, Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булганнар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Байлангар авылының Яшьләр урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Байлангар авылының Ф.Загидуллин, Мәктәп һәм Г.Тукай урамы буенча юлга вак таш салып төзекләндерү , проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- **Байлангар авылы Мәктәп урамына юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;**
- **- Байлангар авылын яктырту өчен лампалар сатып алу**
- **- Байлангар авылы зиратына коймалар алу һәм урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;**
- **- Байлангар авылының урам юлларын карап тоту;**
- **- Байлангар авылының артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу**
- **- Байлангар авылындагы һәйкәлне төзекләндерү (брусчатканы салу, койманы буяу), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелеген гамәлгә ашыру**

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукынаия булган , җыенда катнашучылар исемлегенә, 548 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 287

Тавыш бирүнә тиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен 287 гражданнар җыенында катнашучытавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны таныргa: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Байлангар авылы , Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча

теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булганнар ,80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Байлангар авылының Яшьләр урамы буенча юлга вак таш түшәү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Байлангар авылының Ф.Загидуллин, Мәктәп һәм Г.Тукай урамы буенча юлга вак таш салып төзекләндерү , проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- **Байлангар авылы Мәктәп урамына юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;**
- **- Байлангар авылын яктырту өчен лампалар сатып алу**
- **- Байлангар авылына зиратына коймалар алу һәм урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;**
- **- Байлангар авылының урам юлларын карап тоту;**
- **- Байлангар авылының артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу**
- **- Байлангар авылындагы һәйкәлне төзекләндерү (брусчатканы салу, койманы буяу), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру**

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы И.Х.Минегалиев